**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 5 сентябрь № 637

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге комплексы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыю-лыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 14 гыйнвар, 1 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге комплексы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге комплексы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 14 гыйнвар, 1 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 25 июль, 365 нче; 2009 ел, 19 июнь, 406 нчы; 2010 ел, 12 апрель, 256 нчы; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 май, 349 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге комплексы юнәлештәге «Свияжский» табигый дәүләт тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Свияжский» ДКТТ территориясендә (акваториясендә) рекреацион эшчәнлекне һәм танып белү туристлыгын җайга салу»;

14 нче пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән тыюлыкка йөкләнгән бурычларны үтәүгә, тыюлык чикләрендәге линия объектларын төзекләндерүгә бәйле булмаган, шулай ук Свияжск авылы территориясендә танып белү туристлыгын үстерү чараларын тәэмин итүгә бәйле булмаган линия объектларын төзү һәм төзекләндерү;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\637.docx